РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
АТНИНСКИЙ РАЙОННЫЙ
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ

422750, село Большая Атня,
улица Ш. Марджани, дом 6

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘТНӘ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

422750, Олы Әтнә авылы,
Ш Мәрҗани урамы,6 нчы йорт

Тел./факс: 8(84369)21020, E-mail: atnya@tatar.ru, сайт: atnya.tatarstan.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

«19» марта 2025 № 99

**«Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районының муниципаль мәгариф оешмасы хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү шартлары турында» Татарстан Республикасы Әтнә районы башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы муниципаль мәгариф оешмалары хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү шартлары турында» 2024 елның 05 июлендәге 319 номерлы карары белән расланган Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт мәгариф оешмалары хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү шартлары турында» 2018 елның 31 маендагы 412 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы гомуми белем бирү оешмалары хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү шартлары турында нигезләмәгә үзгәреш кертү хакында» 2025 елның 12 мартындагы 149 номерлы карарын үтәү йөзеннән, Әтнә районы башкарма комитеты карар бирә:

1. «Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы муниципаль мәгариф оешмасы хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү шартлары турында» Әтнә районы башкарма комитетының 2024 елның 5 нче июлендәге 319 нчы номерлы карары белән (Әтнә муниципаль районы башкарма комитетының 21.01.14 номерлы карары белән кертелгән үзгәрешләр белән) расланган Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районының гомуми белем бирү учреждениеләре хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү шартлары турында Нигезләмәгә кушымта нигезендә бирелгән 17 нче таблицаны яңа редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә.

2. Әлеге карарның гамәлдә булуы 2025 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

3. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге хокукый мәгълүматның рәсми порталында (https://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районының рәсми сайтында (https://atnya.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районының финанс-бюджет палатасы рәисенә йөкләргә.

Җитәкче А.Ф. Каюмов

Кушымта
Татарстан Республикасы
Әтнә районы башкарма комитетының
2025 ел 19 нчы мартындагы
99. номерлы карарына

«17 нче таблица

Гомуми белем бирү учреждениеләре җитәкчеләренең хезмәт хакы төркеме, төп окладларның күләмнәре һәм башкарыла торган эшләрнең сыйфаты өчен кызыксындыру характерындагы түләүләр

| Җитәкченең хезмәте өчен түләү төркеме | Күләмле күрсәткечнең әһәмияте (уку елы башына торышы буенча укучылар, тәрбияләнүчеләр саны), кеше <*> | База окладлары, сум | Башкарыла торган эшләрнең сыйфаты өчен кызыксындыру характерындагы түләүләр, сум |
|---|---|---|---|
| 1 | 1 - 15 | 37 000 | 8 000 |
| 2 | 16 - 50 | 39 000 | 8 000 |
| 3 | 51 - 100 | 41 000 | 9 000 |
| 4 | 101 - 200 | 42 000 | 10 000 |
| 5 | 201 - 400 | 43 000 | 11 000 |
| 6 | 401 - 600 | 44 000 | 12 000 |
| 7 | 601 - 800 | 45 000 | 12 000 |
| 8 | 801 - 1 000 | 48 000 | 12 000 |
| 9 | 1 001 - 1 200 | 49 000 | 13 000 |
| 10 | 1 201 - 1 400 | 50 000 | 14 000 |
| 11 | 1 401 - 1 800 | 50 000 | 17 000 |
| 12 | 1 801 һәм югары | 51 000 | 20 000 |

--------------------------------

<*> Ябык типтагы девиант тәртипле укучылар, җинаять-үтәтү системасы төзәтү учреждениеләрендә, шифаханә тибындагы гомуми белем бирү оешмаларында, озак дәвалануга мохтаҗ балалар өчен шифаханә тибындагы гомуми белем бирү оешмаларында, җайлаштырылган белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы гомуми белем бирү оешмаларында укучылар өчен контракты 3 коэффициенты белән исәпкә алына.

Гомуми белем бирү оешмалары каршындагы интернатларда яшәүче укучылар контингенты 2 коэффициенты белән исәпкә алына.

Гомуми белем бирү оешмаларының мәктәпкәчә төркемнәрендә тәрбияләнүчеләр контингенты 1,5 коэффициенты белән исәпкә алына.

Мәктәпара укыту комбинатларының укыту контингенты 0,5 коэффициенты белән исәпкә алына».